| | |
|---|---|
| КИЛЕШЕНГӘН | РАСЛЫЙМ |
| Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе » МУ житәкчесе | Арча муниципаль районы «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| __________И.И.Әюпов | __________М.Ф.Котдусов |

**«Арча читекләре» дип исемләнгән**

**Республика күләм этно-фестиваль үткәрү турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**Максаты һәм бурычлары:**

Фестиваль традицион мәдәниятне, халык иҗатының һәм декоратив-гамәли сәнгатенең иң яхшы үрнәкләрен ачыклау, үзенчәлеген үстерү, онытыла барган борынгы йолаларны, гореф-гадәтләрне торгызу, халык җыр-биюләрен саклап калу, киләчәк буыннарга җиткерү, катнашучы иҗат коллективларына тәҗрибә туплау, читек чигү осталарын, һөнәрчеләрне барлау, күн кәсепчелеген, татар халкының милли аяк киеме - читекне популярлаштыру максатларында үткәрелә.

«Арча читекләре» Республика күләм этно-фестивале Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Арча район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан оештырыла.

**Шартлары:**

1. Фестивальдә вокаль ансамбль, фольклор һәм бию коллективлары, халык музыка уен коралларында уйнаучылар катнаша. Катнашучыларның яше чикләнмәгән. Иҗади коллективлардан бер генә концерт номеры булу шарт.

2. Коллективлар халыкның көнкүрешеннән алынган йола-күренешләрне, гаилә бәйрәмнәре, милли уеннардан торган композицияләр, халык

җырларын һәм биюләрен тәкъдим итәргә тиеш. Фольклор күренешләрнең читек белән бәйле булуы хуплана.

3. Репертуар башкаручыларның яшь үзенчәлекләренә туры килергә, фольклор әсәрне башкару традицияләре сакланырга тиеш. Башкарылучы чыгышта киемнәрнең халык традицияләренә туры килүе шарт.

4. Фестивальнең мәҗбүри шарты – һәр катнашучы коллектив үзе белән сувенир читек (кул эшләнмәсе) ясап алып килергә тиеш. Иң оригиналь кул эшләнмәләренә истәлекле бүләкләр тапшырылачак.

**Фестивальдә катнашу өчен түбәндәге номинацияләр тәкъдим ителә:**

- «Халык җыры» (лирик, уен җырлары, бишек җыры, такмак һ.б.);
- «Халык биюе»;
- «Инструменталь башкару» (гармун, гөслә, кубыз, курай, сорнай, мандолина, думбра һ.б);
- «Фольклор-этнографик күренеш» ( 7 минуттан артмаска тиеш).

**Үткәрү тәртибе:**

Фестивальдә катнашу өчен гаризалар 15 августка кадәр кабул ителә. Фестивальдә катнашырга теләүчеләр тиешле гаризаны «Арча читекләре» дигән язу белән **ardk-metod@mail.ru** электрон почтасына җибәрә. Белешмәләр өчен телефон: 89297280074, Мөхәммәтгалиева Ләйлә Ринатовна

Фестивальне үткәрү вакыты – 2026 елның 21 августы. Үткәрү урыны – Арча шәһәре Үзәк стадионы.

**ГАРИЗА ФОРМАСЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Коллективның тулы исеме | |
| 2. | Коллектив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| 3. | Коллектив җитәкчесенең телефон номеры | |
| 4. | Катнашучылар саны | |
| 5. | Номинация | |
| 6. | Репертуар | |